

Рәсем сәнгатен яратучылар очен чын Яна ел бүләге: Саранскида уникаль рәссам Архип Куинджи күргәзмәсе эшли.
Мордовиянен С.Д.Эрьзи исемендәге музеенда Дәүләт Рус музее (Санкт-Петербург) жыентыгындагыннан XIX гасырнын икенче яртысындагы ин боек рус пейзажистларынын берсе, яктылык сихерчесе, романтик, импрессионизмнын алдынгысы Архип Иванович Куинджинын (1842 - 1910) рәсем күргәзмәсе белән сокланып олгерергә була.

Архип Иванович Куинджи XIX гасырнын ин боек рус рәссамнарынын берсе. Мариупольдән килгән ярлы итекче улы, мохтажлык кичергәннән сон, башкаланын рантьеларына үтеп керә һәм көчеп йорүчеләр жәмгыятенен ин якты йолдызы була. Анын картиналары зур популярлык белән файдаланган, аларны император



гаиләсе әгъзалары һәм танылган коллекционерлар сатып алган, ә күргәзмәләргә чиратлар тезелгән.
Архип Куинджинын ижатын анлар очен, безгә дә шул вакытта дингезендә йозәргә, анын тормыш юлы һәм рәссамнын формалашу этаплары турында белергә кирәк.
Тамашачылар әлеге күргәзмәдә рәссамнын серле «затворничество» чоры әсәрләрен күрә ала. Ул дан апогеенда, котмәгәндә (1882 елдан), үзенен остаханәсендә бервзе кала. Егерме ел дәвамында ачык күргәзмәләрдә катнашмый һәм беркемгә дә үз эшләрен күрсәтми. Бу ябык, унышлы этап искиткеч эшләр белән билгеләнә һәм шуларнын 40ы С.Д.Эрьзи исемендәге музеенда оештырылган күргәзмәдә күрсәтелә.



Архип Куинджинын нечкә итеп язылган пейзажлары, образнын катлаулы романтик – реалистик структурасы һәм кабатланмас автор манерасы белән айнын балкышын, утлы кояш баюын, тан алдын, Салават күперенен, мәһабәт тау түбәләренен балкышын; яктылык уенын тулысынча тапшыручы виртуоз рәвештә гәүдәләндерелгән яктылык тере табигать эффектлары рәссамга доньякүләм танылу китерә. Останын тирән күзәтүле пейзажлары фәлсәфәгә, медитациягә, музыкаль һәм шигъри ассоциацияләргә ия.
Архип Куинджинын сихеренә, талантынын кочена инану авыр түгел: анын әсәрләре күргәзмәсендә музей залында булу житә. Шулай итеп, күренекле останын әсәрләрен 4 февральгә кадәр С.Д.Эрьзя исемендәге республика сынлы сәнгать музеенда күрергә

момкин. *0+*

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**